ГЛАВА СТАРОКАШИРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ КӘШЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**от 20.03.2024г.** **№ 5**

«Иске Кәшер авыл җирлеге Иске Кәшер торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлегенең Яхшыбай торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлегенең Яхшыбай торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлеге Уставының 18.1 статьясына туры китереп, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгы

**КАРАР ИТӘ:**

1.2024 елның 30 мартында 10.00 сәгатькә Татарстан Республикасы, Сарман муниципаль районы, Яхшыбай торак пункты, Мирная урамы, 20а йорт адресы буенча урнашкан Иске Кәшер авылы мәдәният йорты бинасында «Иске Кәшер авыл җирлеге Яхшыбай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлегенең Яхшыбай торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар жыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Иске Кәшер авыл җирлеге Яхшыбай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы, «Сарман муниципаль районы Иске Кәшер авыл җирлегенең Яхшыбай торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«1. Тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Яхшыбай торак пунктында тышкы яктырту челтәрләрен (лампалар, таймерлар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру) ремонтлау
2. Яхшыбай торак пунктында торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) ;
3. Яхшыбай торак пунктында янгынга каршы резервуарлар (янгын сүндерү сулыклары), янгын пирслары (гидрант урнаштыру (махсус техниканы арендалау, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү));
4. Яхшыбай торак пунктында торак пункт территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү); бензокосилка, ЗИЛ-131 автомашинасы, Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы , ЗИЛ-131 автомашинасы өчен запас частьләр сатып алу);
5. Ремонт, коймалар төзү, традицион күмү урыннарын төзекләндерү ( төзелеш материаллары сатып алу һәм койма урнаштыру буенча эш өчен түләү);

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Иске Кәшер авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка чыгарырга, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http://https://sarmanovo.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сарман муниципаль районының
Иске Кәшер авыл җирлеге башлыгы /Р.Н.Дәүләтҗанов/